**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Уразай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Уразай авылы № 52 25 февраль 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының 2012 елның 12 нче октябрендэге 27 нче номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм эш итү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында (27.02.2013 №35, 15.06.2015 №111, 17.08.2018 №106) карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Граждан кодексының беренче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 21 декабрендәге 430-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Уразай авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Советының 2012 елның 12 нче октябрендэге 27 нче номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм эш итү тәртибе турында Нигезләмәгә (27.02.2013 №35, 15.06.2015 №111, 17.08.2018 №106 карарлар редакциясендә), 14.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«14.2. Хуҗасыз күчемсез әйбер исәпкә куелган көннән соң бер ел үткәч, ә линияле объектны исәпкә куйган көннән соң оч ай узгач орган, җирлекнең башкарма комитеты, бу әйбергә муниципаль милек хокукын тану таләбе белән судка мөрәҗәгать итә ала.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: А.М.Шәрифуллина